КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 октябрь г.Казань № 968

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климаты торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1069 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климаты торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1069 нчы карарына, 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«7. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән берлектә, 2023 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча генераль планнарның һәм кагыйдәләрнең актуальлеген һәм 2024 елның 1 гыйнварына кадәр Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына торак пунктлар һәм территориаль зоналар чикләре турында белешмәләр кертүне тәэмин итәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А. В. Песошин